# 1991 елның беренче кварталында районның экономик һәм социаль үсеше буенча дәүләт планнарының үтәлеше йомгаклары

## Промышленность

Беренче кварталда промышленность продукциясенең гомуми күләме узган елның шул чоры белән чагыштырганда 15,5 процентка кимеде.

Промышленностьта хезмәт житештерүчәнлеге 8,3 процентка төште. Эшләүчеләр саны 7,9 процентка кимеде.

Продукция поставкалауның договор йөкләмәсе 79,8 процентка үтәлде.

Район промышленностеның эше түбәндәге мәгълүматлар белән билгеләнә (процентларда).

| | Продукция поставкалау буенча договор йөкләмәләренең үтәлеше. | Кулланучыларга бирелеп житкерелмәгән продукция (мең сум-да). | Продукциянең фактик үсеш темпы күләме |
|---|---|---|---|
| Шикәр заводы | 55,8 | 8199 | —52,7 |
| Ит комбинаты | 100 | — | —11,5 |
| Сөт-май комбинаты | 100 | — | —27,3 |
| Машина төзү заводы | 100 | — | —28 |
| Икмәк заводы | 100 | — | +12,4 |
| Типография | Х | Х | +62,8 |
| Урман промышленносте хуҗалыгы | 100 | — | —18,2 |
| Төзелеш материаллары комбинаты | Х | Х | +28,9 |
| НГДУ | 100 | — | +6,7 |
| Элеватор | Х | Х | +38,8 |
| Барлыгы: | 79,8 | 8199 | —15,5 |

Промышленность буенча тулаем договор йөкләмәләре 79,8 процентка үтәлде. Шикәр заводы договор дисциплинасын бозды һәм кулланучыларга 8199 мең сумлык продукция бирелеп житкермәде.

Икмәк заводы, типография, төзелеш материаллары комбинаты, НГДУ, элеватордан башка барлык промышленность предприятиеләре дә промышленность продукциясе күләме үсеше темпын киметтеләр.

Район промышленносте ваклап сату бәяләрендә 12506 мең сумлык халык кулланугы товарлары житештерде. Бу 1990 елның шул чоры белән чагыштырганда 43,8 процентка ким.

Азык промышленностенда продукциянең аерым төрләрен житештерү түбәндәге мәгълүматларда характерлана (тонналарда):

| | план буенча | фактик | план үтәлеше (%) | планга карата −/+ |
|---|---|---|---|---|
| Шикәр комы | 4350 | 4413 | 101,4 | +63 |
| Төргәксез рафинад | 4550 | 4611 | 101,3 | +61 |
| Төргәктәге рафинад | 100 | 23 | 23 | —77 |
| Колбаса әйберләре | 43 | 45 | 104,7 | +2 |
| Аертылмаган сөт продуктлары (сөткә күчереп исәпләгәндә). | 990 | 1009 | 101,9 | —19 |
| Икмәк әйберләре | 1550 | 1708 | 110,2 | +158 |

Болар белән бергә, уртача хезмәт хакы хезмәт житештерүчәнлеге үсешеннән узып киткән. Анализ промышленность производствосы сферасында уртача айлык хезмәт хакы һәм хезмәт житештерүчәнлеге үсеше темплары 1991 елда 1990 елның шул чоры белән чагыштырганда артып киткән предприятиеләр саны күбрәк булуын күрсәтә.

Бу чорда бер эшләүчегә 13110 сумлык продукция житештерелгән. Моның белән бергә район промышленностенда хезмәт житештерүчәнлеге 8,3 процентка кимегән. Шикәр заводы, ит комбинаты, сөт-май комбинаты һәм машина төзү заводы хезмәт житештерүчәнлеге үсеше темпын киметүгә юл куйдылар.

## Агропромышленность комплексы

Колхоз, совхозларда һәм хуҗалыкара предприятиеләрдә продукция житештерү түбәндәге мәгълүматларда характерлана (центнерларда).

| | 1990 елда | 1991 елда | 1991 елда 1990 елга карата (%) |
|---|---|---|---|
| Ит (тереләй үлчәүдә) | 18372 | 14177 | 77 |
| Сөт | 71342 | 62363 | 87 |

Колхоз, совхозларда һәм хуҗалыкара предприятиеләрдә ит терлекләре үстерү һәм сөт алу кимеде. Мәсәлән, ит житештерү узган елгыдан 4195 центнерга яки 23 процентка, сөт 8979 центнерга яки 13 процентка кимегән.

Ел башыннан бер сыердан сөт алу 1990 елдагы 713 килограмм урынына 624 килограмм тәшкил итә.

Терлекчелек продуктлары сату түбәндәге мәгълүматларда билгеләнә (центнерларда).

| | 1990 елда | 1991 елда | 1991 елда 1990 елга карата (%) |
|---|---|---|---|
| Терлек һәм кошлар (тереләй үлчәүдә) | 24333 | 21711 | 89 |
| Сөт | 63700 | 50594 | 79 |
| Шул исәптән: договор буенча гражданнардан жыелганнан тыш | 59024 | 48221 | 82 |

Беренче кварталда договор контрактациясе терлекләр һәм кошлар буенча 78, сөт—86 процентка үтәлгән.

17 хуҗалык терлекләр һәм кошлар сату күләмен киметте, яки дәүләткә 494 тонна ит (тереләй үлчәүдә) бирелеп житкерелмәгән.

28 хуҗалык сөт сатуны узган елгы дәрәҗәдән киметүгә юл куйдылар, яки 262,2 тонна сөт бирелеп житкерелмәде. Кайбер хуҗалыклардан сатып алынган сөтнең сыйфаты түбән. Мәсәлән, Муса Җәлил исемендәге, «Таң», Кузнецов исемендәге, «Родина», «Знамя Октября» колхозларының район буенча беренче сортлы сөт 86 процент булганда, дәүләткә саткан сөтләренең 56—82 проценты гына беренче сортлы иде.

«Төрнәс» совхозында сөтнең майлылыгы түбән. Шуңа да алар барлыгы 44 процент сөтне генә беренче сорт белән саттылар, ә икенче сортлы сөтләре 53 процент тәшкил итте. «Знамя Октября», Кузнецов исемендәге колхозлардан сөтнең 56 проценты беренче, 44 проценты икенче сорт белән генә кабул ителде.

Колхоз, совхозларда, хуҗалыкара предприятиеләрдә малларның продуктлылыгы түбәндәге мәгълүматларда характерлана:

| | 1990 елда | 1991 елда | 1991 елда 1990 елга карата (%) |
|---|---|---|---|
| Мөгезле эре терлекләр | 36422 | 34502 | 94 |
| Шул исәптән сыерлар | 10000 | 10000 | 100 |
| Дуңгызлар | 34906 | 31505 | 90 |
| Сарыклар | 41376 | 39002 | 94 |

1991 елда мөгезле эре терлекләр саны 1990 ел белән чагыштырганда 1920 башка, яки 6 процентка, дуңгызлар 3401 баш яки 10 процентка, сарыклар 2374 баш, яки 6 процентка кимеде.

Колхоз-совхозларда һәм хуҗалыкара предприятиеләрдә терлекләрдән уртача тәүлеклек артым алу күрсәткече түбән булуында кала килә. Мәсәлән, ел башыннан барлык төр мөгезле эре терлекләрдән уртача тәүлеклек үсеш 513, дуңгызлар 340 грамм тәшкил итте. «Төрнәс», «Сөлчә» совхозларында артым алу аеруча түбән. Аларда мөгезле эре терлекләрдән уртача тәүлеклек үсеш 400, дуңгызлардан 300 граммнан да ким.

Авыл җирләрендә продукт бирүче малларның баш саны түбәндәгечә:

| | 1990 елда | 1991 елда | 1991 елда 1990 елга карата (%) |
|---|---|---|---|
| Мөгезле эре терлекләр | 11821 | 11916 | 101 |
| Шул исәптән сыерлар | 5582 | 5690 | 102 |
| Дуңгызлар | 2186 | 2512 | 115 |
| Сарыклар һәм кәҗәләр | 24222 | 22196 | 92 |

1991 елда авыл җирләрендә шәхси хуҗалыклардагы мөгезле эре терлекләрнең баш саны 1990 елдагыдан 95 башка, яки 0,8 процентка, шул исәптән сыерлар 102 башка, яки 1,7 процентка, дуңгызлар 326 башка, яки 4,9 процентка артты.

Әмма Биләр Озеро, Елаур, Колбай Мораса, Иске Әлмәт, Бикүле, Тимерлек, Төрнәс авыл Советларында барлык төр терлекләрнең дә баш санын киметүгә юл куйдылар.

## Капиталь төзелеш

Финанслауның барлык чыганакларыннан чыгып төп фондларны хәрәкәткә кертү 48020 мең сум тәшкил итте. Бу узган елның шул чорындагы белән чагыштырганда 14,6 процентка күбрәк. Дәүләт предприятиеләре һәм оешмалары 9013 мең сумлык капиталь салулар үзләштерделәр, яки ул узган елгы шул чор белән чагыштырганда 2892 мең сумга күбрәк. Производство билгеләмәсендәге объектларга дәүләт капиталь салулар күләме узган ел белән чагыштырганда 1741 мең сумга үсте.

Колхозлар һәм хуҗалыкара предприятиеләр средствосына төп фондларны сафка кертү 933 мең сум тәшкил итте. 1642 мең сумлык капитал салулар үзләштерелде. Шуның 1247 мең сумы производство фондына салынды.

Төзү-монтаж оешмаларының үз көчләре белән үткәрелгән подряд эшләре күләме 5288 мең сум тәшкил итте, 1990 елгыдан 15,7 процентка азрак. Бу түбәндәге мәгълүматларда чагыла (мең сумнарда).

| Предприятие һәм оешмалар | Үз көчләре белән башкарылган подряд эшләре: 1991 елда | 1990 елда | Үсеш темпы (проц.). |
|---|---|---|---|
| 53 нче СМУ | 640 | 1159 | 55,2 |
| Норлат-Октябрь ПМКсы | 430 | 427 | 100,7 |
| ДПМК | 178 | 178 | 100,0 |
| 127 нче ПМК | 289 | 381 | 75,9 |
| УРСЖ | 49 | 42 | 116,7 |
| «Таткоопстрой» СУсы | 66 | 71 | 93 |
| МСО | 1988 | 2001 | 99,4 |
| ДРСУ | 916 | 906 | 101,1 |
| «Татжилгражданстрой» РСУы | 524 | 577 | 90,8 |
| «ТНГФ» ПМКсы | 208 | 533 | 39 |
| Барлыгы район буенча | 5288 | 6275 | 84,3 |

Төзелештә хезмәт житештерүчәнлеге 6,8 процентка төште. МСО, ДРСУ, «Татжилгражданстрой» тресты РСУы һәм Норлат-Октябрь ПМКсыннан башка барлык төзелеш оешмалары да хезмәт житештерүчәнлеген киметүгә юл куйдылар.

## ХАЛЫКНЫ ТОВАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ

Дәүләт һәм кооператив сәүдәдә ваклап сату товар әйләнешенең быелның беренче квартал планы 121,1 процентка үтәлде. Ул узган елның шул чоры белән чагыштырганда 4082,9 сумга яки 25,9 процентка артты.

Кооператив сәүдәсендә аерым товарларны сату түбәндәге мәгълүматларда күрсәтелә (мең сумнарда).

| | 1991 елның I кварталында сатылган | 1991 елның I кварталына 1990 ел белән чагыштырганда (%). |
|---|---|---|
| Икмәк продуктлары | 478,7 | 124,3 |
| Аерытылмаган сөт продуктлары | 150,3 | 103,4 |
| Сыр | 15,2 | 76,0 |
| Терлек мае | 146,8 | 80,2 |
| Үсемлек мае | 37,5 | 75,0 |
| Маргарин продуктлары | 150,3 | 103,4 |
| Ит һәм ит продуктлары | 262,1 | 130,7 |
| Балык һәм балык продуктлары | 12,1 | 13,1 |
| Шикәр | 391,3 | 112,4 |
| Кондитер әйберләре | 413,2 | 100,8 |
| Яшелчә | 93,9 | 8 тапкыр |
| Кием һәм эчке киемнәр һәм тукымалар | 3173,8 | 123,1 |
| Трикотаж әйберләре | 441,3 | 119,5 |
| Сабын һәм синтетик юу средстволары | 98,3 | 86,4 |
| Спорт товарлары | 108,0 | 3 тапкыр |
| Телевизор һәм музыка товарлары | 5,4 | 49,1 |
| Радиотоварлар | 339,8 | 72,0 |

Беренче кварталда халыкка 1837,8 мең сумлык, узган елның шул чорындагыдан 202,8 мең сумга күбрәк хезмәт күрсәтелгән. Предприятие һәм оешмалар 87,0 мең сумлык кондициясез әйберләр товарлары сатканнар. Бу хезмәт күрсәтүнең гомуми күләменең 4,7 процентынa кадәр. Хезмәт күрсәтүнең специальләшкән предприятиеләре 588,4 мең сумлык хезмәт күрсәткәннәр. Бу узган елның шул чорындагыдан 11,3 процентка күбрәк.

**Дәүләт статистикасының район бүлеге.**

### • *«Дуслык» газетасы призына*

# Игътибар: ярыш

5 май—матбугат көненә багышлап районда «Дуслык» газетасы призына традицион җиңел атлетика буенча катнаш эстафета үткәрелә. Ярыш Норлат шәһәрендә 1 май—массовый күңел ачу көнендә оештырылачак.

Тренировка һәм врачтан рөхсәте буенча барлык оешмалар, район мәктәпләре командалары да ярышка чакырыла.

Катнаш эстафетаның программасы түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

I этап—(ирләр)—400 метр.
II этап—(хатын-кызлар)—200 метр.
III этап—(ирләр)—400 метр.
IV этап—(хатын-кызлар)—200 метр.
V этап—(ирләр)—200 метр.
VI этап—(хатын-кызлар)—100 метр.

Барлыгы 1500 метр араны үтәргә кирәк.

Урыннарны билгеләү тәртибе һәм шартлары гомуми: беренче этапта катнашучылар эстафета таякчыгын икенче этаптагыларга, икенчеләр—өченчегә тапшыралар һәм шулай дәвам итә. Эстафетада иң беренче урынга чыгучы команда җиңүче итеп билгеләнә, бер урын алучы команда кубок һәм грамота, катнашучылар—кыйммәтле призлар һәм грамоталар белән, ә икенче, өченче урыннарны алучылар грамоталар белән бүләкләнәчәкләр.

Врач имзасы булган заявкалар ярыш көнне судьялар коллегиясенә бирелә. Ярышлар сәгать 11дә башлана.

Шул ук көнне шикәр заводы стадионында башка төрле ярыш—футбол буенча блиц-турнир үткәреләчәк. Уеннар 15 әр минутлык ике таймнан төшеп калу системасы буенча алып барыла. Теләге булган барлык командалар да турнирга чакырыла.

Старт һәм финиш үзәк мәйданнан бирелә.

### • *Кызык та, кызганыч та*

# Һәркемгә—үзенеке

Караклар дөньясында шулай күнелгән инде: һәр җинаятьче бары тик билгеле бер шөгыль «үз эше» белән мәшгуль. Тикшерүчеләр арасында да шулай ук, һәр тикшерүче билгеле бер төрдәге җинаять буенча тикшерү алып бара. Димәк, алар—тикшерүче һәм җинаятьче очрашырга тиешләр.

Норлатта яшәүче З. Н. Гарифуллин күп тапкырлар Димитровград шәһәреннән аракы ташып, Норлатта аның бәясен арттырып сата, кыскасы, спекуляция белән шөгыльләнә.

Октябрь районы эчке эшләр бүлеге тикшерүчесе, милиция майоры В. А. Трифоновка озак елларга сузылган хезмәтендә шуңа охшаш эшләрне байтак тикшерергә туры килә.

Менә алар очраштылар... Тикшерүче сорау бирде. Гарифуллин җавап бирде. Тикшерүче дәлилләр китерде. Гарифуллин үз гаебен танырга мәҗбүр булды.

Тикшерүче эшне судка җибәрде һәм яңа эшкә алынды.

Гарифуллин өенә кайтты һәм аракы сатмау турында имзасын куйганга күрә, яңа эшкә тотынды—самогон куу белән шөгыльләнә башлады...

Ярый инде, бусы башка вакыйга... һәм башка тикшерүче белән...

М. ТӘМАЕВ.



Киттек шулай базарга.

## СПОРТ

## ВОЛЕЙБОЛ

Чистай шәһәрендә 19ыннан 21 апрельгә кадәр волейбол буенча республика зона ярышы булды. Анда Чистай, Алексеевск, Яңа Чишмә, Аксубай, Әлки, Октябрь, Куйбышев районнары командалары катнашты.

Уеннар ике подгруппада үткәрелде. Алексеевск, Куйбышев, Октябрь районнары командалары үз группаларында отып финалга чыктылар. Беренче, икенче урын өчен кискен көрәштә безнекеләр чистайлыларга оттырдылар һәм икенче урынга чыктылар.

Т. КАМАЛЕТДИНОВ.

## ӨСТӘЛ ТЕННИСЫ

21 апрельдә НУРБның «Нефтяник» спортзалында өстәл теннисы буенча район беренчелегенә шәхси команда ярышлары үткәрелде. Ярышта районның көчле теннисчылары көч сынаштылар.

АТП, 1 нче мәктәп, НУРБ командалары арасында көрәш кискен барды. Кискен көрәштә НУРБ командасы җиңү яулады. Икенче урынга беренче мәктәп, өченчегә АТП командалары чыкты. «Правда», Синдряков исемендәге колхозлар командаларының яхшы уйнауларын билгеләп үтәргә кирәк.

Аннан соң шәхси беренчелек өчен көрәш башланды. Хатын-кызлар арасында яшь туристларның район станциясеннән А. Хәйретдиновага тиңнәр булмады. Икенче урынга В. Абрамова («Правда» колхозы), өченчегә Г. Будяшкина (Синдряков исемендәге колхоз) чыкты.

Ир-егетләр арасындагы ярышта М. Вәлиәхмәтовны (АТП) җиңеп МСОдан Г. Киргизов финалга чыкты һәм район чемпионы исемен яулады. Өченче урынны музыка мәктәбе директоры Т. Бадыйгин алды.

Җиңүчеләр призлар һәм Мактау кәгазьләре алдылар.

Х. ФАТУЧЕВ.

### • *Футбол күзәту*

# Сезон ачылу алдыннан

2 майда Алатыр шәһәрендә җирле футболчылар белән очрашып «Факел» командасы сезонны ачып җибәрә. Ул сәяхәт барышында якташларыбыз РСФСР беренчелегенә зона ярышларының икенче очрашуын шул ук Чувашия ССР башкаласы—Чабаксар командасы белән 4 майда уздыралар.

Сезон ачылу алдыннан «Факел»ның начальнигы Г. И. Шугаев белән очраштык. Ул менә ниләр сөйләде.

—Якташларыбыз Новороссийскида икенче җыеннан кайттылар. Икенче җыен барышында уенчылар арасында элемтәләр буенча күнегүләргә басым ясалды. Берничә команда белән иптәшләрчә очрашулар да уздырылды.

Команда сезонга хәзерләнгәндә Норлатта да шундый ук эшләр алып барылды. Стадионны киртәләгән коймалар төзәтелде, аңа су сиптерү өчен сууткәргеч сузылды. Хәзер аны радиолаштыру алып барыла, өстәмә трибуналар ясала һәм башка төр хәстәрлекләр күрелә.

Григорий Иванович фикеренә кушылып бер нәрсәне генә өстисе килә:футбол сөючеләр «Факел» белән очрашасы көннәргә дә күп калмады инде. 9 майда 15 сәгатьтә Бөек Җиңү көнендә шәһәр стадионында футбол сезоны ачылуга багышланган тантана була. Тантана күңелле спорт программасы белән ачыла. Ул тәмамлангач Йошкар-Оланың «Буревестник» командасы белән очрашу була. Бу уңайдан әйткәндә ул ял көннәренең чираттагысында 11 майда 17 сәгатьтә «Факел» Алабуга «Торпедо»сын да үз кырында кабул итә.

Бәйрәм көннәрендә әнә шулай спорт сөючеләрне кызыклы очрашулар көтә. Уеннарга рәхим итегез, якташлар!

Р. АЙЗАТУЛЛИН.

## КӨЛЕШЕП АЛЫЙК

**ТӨЗҮЧЕ ХИСМӘТ**

Төзелештә
Кирәкләр юк.
Бер эш бармый, хикмәт
шунда.
Көрәп-көрәп эш хакы
алган—
җырлап кайта Хисмәтулла.

**ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ**

Депутат
итеп сайладык—
вәгъдәсе торган шуннан:
Сайлаганда —бик күп
сөйләү,
бик аз эшләү—соңыннан.

# Газ колонкасыннан файдалану кагыйдәләрен үтәгез

Газ колонкасы иң уңай һәм тиз су җылыту чарасы булып тора. Ләкин аңардан белмичә файдалану исле газ белән агулануга китерә.

Исегездә тотыгыз: төтен юлында тарту көче, вентиляция каналы һәм колонка урнашкан бүлмәгә һава агымы кергәндә генә колонкадан куркынычсыз файдалану мөмкин булачак.

Төтен юлындагы тарту көчен колонканы кабызганда да, сүндергәндә дә тикшерергә кирәк. Аның өчен тартуны яба торган калпак астына кабызган шырпыны китереп карыйлар. Әгәр дә ялкын кире як-якка тартылса тарту юк һәм шунлыктан колонкадан файдалану катгый рәвештә тыела.

Өйдә газ исе чыкса газ приборларыннан файдаланмагыз, ут кабызмагыз, тәмәке тартмагыз, электроприборларны кабызмагыз һәм сүндермәгез, приборларның краннары ябылуын тикшерегез, бүлмәне җилләтегез.

Төзексез колонкадан файдаланырга ярамый. Бу тормыш өчен куркыныч белән яный.

Авария диспетчер службасын 2—28—58 телефоны белән чакырыгыз. Ул тәүлек әйләнәсендә эшли. Газ приборларын ремонтлау буенча да шул ук телефон буенча шалтыратыгыз.

«Лениногорск» газ идарәсенең Норлат газ службасы.



# „Олимпиада-91"

Якушкино урта мәктәбе укучылары Чабаксар шәһәрендә үткәрелгән чуваш теле һәм әдәбияты олимпиадасында катнаштылар. Бирегә Чувашия, Татарстан, Башкортстан республикалары, Ульяновск һәм Самара өлкәләренең 37 районыннан 800 укучы җыелган иде. Якушкино мәктәбе укучылары Татарстаннан катнашучы бердәнбер вәкилләр иде. Әйтергә кирәк,ярышучылар арасында аз санлы булуына да карамастан, алар шактый уңышлы чыгыш ясадылар.

Олимпиадада һәр район вәкиле җиде төрле конкурста катнашты. Туган якны өйрәнүчеләр конкурсында 2 нче класс укучысы Елена Ермилова беренче урынны алды. Ә Людмила Парукова һәм Надежда Семенова, шулай ук 2 нче класс укучылары, шигырь укучылар конкурсында I нче урынны яуладылар. Елена Ермилова һәм Надежда Семенова, берсе кул эшләре әйберләрен, икенчесе милли киемнәр күрсәтү конкурсында икенче урыннарга лаек булдылар. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк. Надя күрсәткән хушпу иң борынгы баш киеме дип табылды.

Стена газеталары буенча конкурста безнең «Чишмә» әдәби газетабыз 4 нче урынга чыкты.

Олимпиадада катнашуыбыз икенче яктан да файдалы булды: укучылар башка яклардан килгән яшьтәшләре белән дуслаштылар, шәһәрнең культура тормышы белән дә таныштылар: театрда спектакльләр карарга, музейларда булырга өлгерделәр.

П. АЛЯКИМОВ,
Якушкино мәктәбенең чуваш теле укытучысы, группа җитәкчесе.

МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.

Учредительләр— халык депутатларының Октябрь район Советы һәм КПССның район партия оешмасы.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Нурзия ФӘСХЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор— ЗӨЛФИЯ ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак. Заказ 49. Тираж 3.350.